**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе һәм вазыйфа атамаларының үзгәрүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты төзү турында» 2016 елның 11 гыйнварындагы ПУ-1 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 16 июнендәге ПУ-504 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2018 елның 6 июлендәге ПУ-473 номерлы һәм 2019 елның 19 апрелендәге ПУ-241 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) оештыру комитеты составыннан Ф.С. Габделганиевны, Р.И. Вәлиевны, Г.Р. Нигъмәтуллинаны, И.Ә. Фәйзуллинны, А.А. Фоминны, Р.А Шәйхетдиновны чыгарырга;

б) оештыру комитеты составына кертергә:

Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызын – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисен (килешү буенча);

Низамова Ләйсән Габделхан кызын – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгын;

Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улын – Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесен;

Хәйруллин Айрат Ринат улын – Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрын;

Хәнифов Фәрит Мөдәррис улын – Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрын;

Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улын – Татарстан Республикасы икътисад министрын;

в) оештыру комитеты әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

И.Ю. Әминовның – «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)»;

Ә.С. Гобәйдуллинның – «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча)»;

Р.З. Закировның – «Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе (килешү буенча)»;

А.Р. Зариповның – «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе (килешү буенча)»;

Р.С. Хәкимовның – «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты фәнни җитәкчесе (килешү буенча)»;

Ә.Г. Юлашевның – «Россия ветераннар берлеге» Бөтенроссия ветераннар иҗтимагый оешмасының «Татарстан Республикасы ветераннар берлеге» республика ветераннар (инвалидлар) иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ — АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2020 ел, 10 июль
№ ПУ-391